ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАР

29 сентябрь 2021 ел № 77

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2017 елның 2 августындагы 105 номерлы карары белән расланган тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә Нурлат муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затка бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны электрон рәвештә формалаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында»2019 елның 16 декабрендәге 439 - ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2017 елның 2 августындагы 105 номерлы карары белән расланган тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә Нурлат муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затка бер тапкыр бирелә торган түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә, Нигезләмәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«6. Муниципаль вазыйфаны биләүче затны бер мәртәбә бүләкләү күләмен билгеләү өчен җирле үзидарә органы (муниципаль орган) Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына түбәндәге документларны тапшыра:

-айлык акчалата түләү турында белешмә, акчалата бүләкләү турында;

-муниципаль вазыйфадагы эш стажы турында җитәкче һәм кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган белешмә;

-хәрби билет күчермәсен (булган очракта), кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе яисә хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе А.С. Әхмәтшин